Безнен һәрберебезнен ерак балачакта доньяны ачкан телнен мәгънәсен бәяләv авыр. Ана телендә гаиләдә әкиятләр сойләделәр, йорәккә кадерле почмакта жырлар жырладылар, анын ярдәмендә без тирә-юньдәгеләр белән аралашырга ойрәндек. Ләмберәнен беренче урта мәктәбе 3 «А» сыйныф укучылары туган татар һәм мордва телләре укытучылары Алмаз Кериш кызы Янгляева белән Марина Витальевна Пирогова, шулай ук мәктәпнен педагог-оештыручысы Зульфия Захир кызы Сюбаева белән бергә “Алмаз” каршындагы фольклор vзәгендә кунакта булганнар.   Балаларны vзәк житәкчесе Альфия Асым кызы Максимова жылы каршы алган һәм ул татар ое буйлап мавыктыргыч экскурсия vткәргән. Үзәк хезмәткәрләре татар конкvреше атмосферасын янарта алганнар: монда пичбашы – балалар йортынын яраткан урыны, хужалык байлыгы салынган сандык, бишек... Балалар зур кызыксыну белән экспонатлар арасындагы бишекне караганнар. Укучыларга тәкъдим ителгән милли костюмнар ошаган. Альфия Асым кызы балаларга татар халык әкиятләрен укыган, “Тvбәтәй” татар уены уйнаганнар, шигырьләр яттан укыганнар, жырлаганнар, биегәннәр – милли мәдәният кочагында булып кайтканнар.